РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 08 » 04 2025 ел №328

«2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында спорт һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында»гы 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, "Физик культура һәм спорт турында"гы 08.10.2008 ел, № 99-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү" Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»гы 2019 елның 5 мартындагы 159 санлы карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, спортның культивацияләнә торган төрләрен үстерү өчен шартлар тудыру, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының спорт абруен күтәрү һәм ныгыту өчен җыелма командалар булдыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. «2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында спорт төрләрен һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасын (алга таба - программа) раслау турында"гы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 01.04.2025 елның № 312 санлы карары белән расланган «2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында спорт төрләрен һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспортының "Елларга бүлеп Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары" бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>Елларга бүлеп Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td>
<td>Программаны финанслау муниципаль, республика бюджетлары һәм җәлеп ителгән акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.
<table>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру еллары</td><td>1 ел/ мең сумнарда</td><td>2 ел/ мең сумнарда</td><td>3 ел/ мең сумнарда</td><td>Барлыгы мең сумнарда</td></tr>
<tr><td>Барлык чыганаклар буенча</td><td>48 167,8</td><td>53 198,00</td><td>56 133,8</td><td>157 498,8</td></tr>
<tr><td>Ютазы муниципаль районы бюджеты акчаларыннан</td><td>45 136,8</td><td>50 398,0</td><td>53 333,8</td><td>148 868,6</td></tr>
<tr><td>ТР бюджеты акчаларыннан спортны үстерүгә</td><td>230,2</td><td>-</td><td>-</td><td>230,0</td></tr>
<tr><td>Шул исәптән балалар-яшүсмерләр спортын үстерүгә</td><td>230,2</td><td>-</td><td>-</td><td>230,0</td></tr>
<tr><td>Спорт чаралары</td><td>1 200,00</td><td>1 200,00</td><td>1 200,00</td><td>3 600,00</td></tr>
<tr><td>Өстәмә җәлеп ителгән акчалар</td><td>1 600,0</td><td>1 600,0</td><td>1 600,0</td><td>4 800,0</td></tr>
</table>
Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле елга һәм план чорына Ютазы муниципаль районы бюджеты һәм авыл җирлекләре бюджетлары проектын формалаштырганда ел саен расланырга тиеш.<br>Җирле бюджетларның һәм бюджеттан тыш чыганакларның акчалары ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.</td>
</tr>
</table>

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе С.П. Самонина

Р.А. Галләмова

т. 2-42-10